# Балачак күге

1) Яратам болытлар күзләргә,
   Болытта сурәтләр эзләргә.
   Болытлар агалар, агалар, —
   Сурәтләр үзгәрә баралар.

   Кушымта:
   Ак болыт, күк болыт
   Агыла күк тулып, —
   Йә оча кош булып,
   Йә чаба ат булып, ак болыт.
   Бик ерак илләргә,
   Дөньялар иңләргә
   Китәр күк балачак
   болытка утырып, утырып.

2) Чакырам болытлар күзләргә,
   Тылсымлы дөньялар гизәргә.
   Болытлар агыла, агыла, —
   Болытта хыяллар чагыла.

   Кушымта:
   Вап-пап- парампапам, вап-пап парампампапам,
   Китәрмен күк очып, болытка утырып, утырып.